**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авыл җирлеге Советы**
# КАРАРЫ

Әсәй авылы № 16-7 «18» декабрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының2010 елның 13 маендагы 129-53 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнарын сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге гражданнарын сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә

Әсәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Советының2010 елның 13 маендагы 129-53 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әсәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнарын сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге гражданнарын сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләре һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 23 статьяның 1 пунктын «яки муниципаль берәмлек халкы» сүзләре белән тулыландырырга.

1.2. 8 статьяның 1 пунктын:

а) түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга: «Гражданнардан сорашып белешү үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланылырга мөмкин»;

б) түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Ә. Идрисов